| «Согласовано» Руководитель МО | «Согласовано» Заместитель директора по УВР | «Утверждено» Руководитель МБОУ «Гимназия №36» |
|---|---|---|
| ____________ А.М.Зайнуллина | ____________ Д.Н.Хакимуллина | ____________ Т.П.Матлина |
| Протокол № 1 | | Приказ № 91-о |
| «28» 08 2019 г. | «28» 08 2019 г. | «29» 08 2019 г. |

**ОЦЕНОЧНЫЕ МАТЕРИАЛЫ**

**РОДНОЙ ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК**
**(для изучающих татарский язык как родной)**

**1 – 4 классы**

**1 класс**

Йомгаклау диктанты

Кунакка

Бүген Фәрит кунакка бара. Ул Булатка кзыклы китап бүләк итте. (10 сүз)

**2 класс**

Кереш диктант

Зөһрә

Зөһрә - укучы. Аңа сигез яшь. Ул иртә тора, чәчен тарый, юына һәм ашый. Мәктәптән кайткач, дәресләр әзерли. Зөһрә - тырыш бала. (20 сүз)

Диктант

Урманда

Кыш килде. Көннәр бик салкын. Хәзер урманда бик матур. Агачлар ак. Куяннар да ак тун кигән. Хайваннарга кышын салкын (19 сүз)

Йомгаклау диктанты

Җәйге каникулда

Җәй җитте. Җәй көне җылы. Мин җәй каникулда авылга кайтам. Анда минем дусларым бар. Без бергә уйныйбыз, урманга йөрибез. Урманда җиләк, гөмбә җыябыз.

**3 класс**

Кереш диктант

Хәйләкәр балык

Алмаз балык тотты. Аны чиләккә салды. Песи балыкны тотмакчы иде. Балык җитезрәк булып чыкты. Тешләре белән песине эләктереп алды (19 сүз)

Диктант

Ял көне

Рөстәм әтисе белән күлгә барды. Күл буенда наратлар үсә. Болында чәчәкләр үсә. Рөстәм әтисе белән су коенды. Ял көне күңелле үтте. (21 сүз)

Йомгаклау диктанты

Мәктәп янында зур бакча бар. Анда укучылар эшлиләр. Дәрестән соң балалар бакчага чыктылар. Малайлар карлыган, чия, ә кызлар яшелчәләр утыртылар. Бергә су сиптеләр. Бакча матур булды. (25 сүз)

Изложение

Минем әбием

Минем әбиемне бик яраталар, чөнки ул кешеләргә ярдәм итергә тырыша. Ул йомшак күңелле, кешеләрне дә яхшы аңлый.
Авылыбыз янында урман бар. Җәй көне әбием урманга йөри. Аның белән мин дә барам. Ул мине файдалы үләннәр җыярга өйрәтә.
Августта мин шәһәргә китәм. Кыш көне туганнарымны, танышларымны үләннәр белән дәвалыйм. Бөтен кеше әбиемә рәхмәт әйтә. (53 сүз)

**4 класс**

Кереш диктант

Минем апам

Минем апам бар. Аның исеме – Зөһрә. Ул унынчы сыйныфта укый. Апам бик яхшы укый. Алар бер сыйныфта укыйлар, бер йортта яшиләр. Минем апам укытучы булырга тели. (26 сүз)

Диктант

Урманда төрле агачлар үсә. Кайбер агачлар бик юан һәм бик озын булып үсәләр. Яфраклы агачлар озак яши. Юкәләр һәм каеннар йөз ел үсә.
Урманның дусты агачларны сындырмый, яфракларны өзми. Ул урманда ут якмый, чүп ташламый. (36 сүз)

Йомгаклау диктанты

Минем энем

Минем кечкенә энем бар. Аның исеме – Марат. Аңа биш яшь. Ул бик матур малай. Маратның чәче кара, күзләре дә кара.
Без Марат белән өйдә дә, урамда да бергә уйныйбыз. Ул машиналар белән уйнарга ярата. Аның машиналары белән уйнарга ярата. (38 сүз)

**Нормы оценивания**

**2-4 классларда диктанталарны бәяләү.**

Хатасыз яки тупас булмаган 1 хата җибәрелгән, дөрес каллиграфия белән матур итеп язылган эшкә «5» ле куела.
3 тән  артык хата булмаган һәм пөхтә итеп язылган; хатасыз, ләкин төзәтүләр белән бик үк пөхтә язылмаган эшкә «4» ле куела.
5 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә «3» ле куела

**2-4 классларда изложениеләрне бәяләү.**

Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә, хаталар булмаса яки 1 орфоргафик (1 җөмлә төзелешендә) хата җибәрелсә, «5» ле куела.
Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса яки пөхтә башкарылып, эзлеклелек булып та, сүз сайлауда һәм җөмлә төзүдә 2-3 хата булса, «4» ле куела.
Текстның яки рәсемнең төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса; 4-6 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда һәм җөмләләр төзегәндә, 4-5 төгәлсезлек китсә, «3» ле куела
Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса; 7-10 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда, җөмләләр төзегәндә, 6-7 хата китсә, «2» ле куела.